**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**АТНИНСКИЙ РАЙОННЫЙ СОВЕТ**

422750, село Большая Атня, улица Советская, дом 38

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ӘТНӘ РАЙОН СОВЕТЫ**

422750, Олы Әтнә авылы, Совет урамы., 38нче йорт

Тел.: 8(84369)21004, факс: 8(84369)21020, E-mail: atnya@tatar.ru, сайт: atnya.tatarstan.ru

РЕШЕНИЕ КАРАР

12 август 2022 № 133

**Әтнә муниципаль район Советының**
**2021 елның 15 декабрендәге 90 номерлы**
**«Әтнә муниципаль районының 2022 елга**
**һәм 2023, 2024 елларның планлы чорына**
**бюджеты турында»гы**
**карарына үзгәрешләр кертү турында**

Әтнә муниципаль районы Финанс-бюджет палатасы рәисе Гыймадиев Ф.И. докладын тыңлаганнан һәм фикер алышканнан соң, Әтнә муниципаль районы Советы карар итте:

1). 1,3,4 һәм 10 статьяларын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

Статья 1.

1. 2022 елга Әтнә муниципаль районы бюджетының төп характеристикаларын расларга:

а) Әтнә муниципаль районы бюджетының фаразланыла торган керем күләме 514353,0 мең сум күләмендә.;

б) Әтнә муниципаль районы бюджеты чыгымнарының гомуми күләме 525032,5 мең сум.;

в) Әтнә муниципаль районы бюджеты кытлыгы 10679,5 мең сум.

2. 2022 елга Әтнә муниципаль районы бюджет кытлыгын финанслау чыганакларын әлеге карарның 1 нче кушымтасы нигезендә расларга.

3 Статья

Әтнә муниципаль районы бюджетында 2022 елга Әтнә муниципаль районы бюджетының фаразланган керем күләмен әлеге карарның 2 нче кушымтасы нигезендә исәпкә алырга.

4 Статья

1. Әлеге карарның 3 нче кушымтасы нигезендә Әтнә районы бюджетының бюджет ассигнованиеләрен 2022 елга бюджет чыгымнары классификациясенең чыгымнар төрләре бүлекләре, бүлекчәләре, максатчан

статьялары (муниципаль программалар һәм программага карамаган эшчәнлек юнәлешләре) буенча бүлүне үзгәртергә.

2. 2022 елга Әтнә муниципаль районы бюджеты чыгымнарының ведомство структурасын әлеге карарның 4 нче кушымтасы нигезендә үзгәртергә.

10 Статья

Әлеге карарның 8 нче кушымтасы нигезендә, 2022 елда Татарстан Республикасы бюджетыннан алына торган бюджетара трансфертларны Әтнә муниципаль районы бюджетында үзгәртергә.

2) Әтнә район башкарма комитетының «Өстәмә акча бүлеп бирү турында»гы карарларын расларга.:

№ 143, 05.05.2002 ел; № 153, 12.05.2002 ел; № 165, 27.05.2002 ел.;

№ 167, 01.06.2002, № 204, 05.07.2002 ел; № 217, 26.07.2002 ел.

3) әлеге карарны Әтнә муниципаль районының рәсми сайтында www.atnya.tatarstan.ru., Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында www.pravo.tatarstan.ru урнаштырырга

Әтнә муниципаль районы башлыгы, Г.Г. Хәкимов
Әтнә район Советы рәисе